# КАРАР

**23 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 23 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

1. «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Лельвиж авылы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру
- Лельвиж авылында, юлларга вак таш салып, чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, юл кырыен куаклардан һәм агачлардан чистарту;
- трактор тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү)
- Лельвиж авылында су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау
- урам яктыртуны карап тоту (Лельвиж авылында урам яктыртуны көйләү өчен урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм ремонтлау)
- Лельвиж авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;
- мотопомпа сатып алу
- Лельвиж авылында су суырту манарасын урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү
- спорт инвентаре сатып алу
- Авыл көне бәйрәме үткәрү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 392 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 198 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 195 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 3 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Лельвиж авылы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру
- Лельвиж авылында, юлларга вак таш салып, чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, юл кырыен куаклардан һәм агачлардан чистарту;
- трактор тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү)
- Лельвиж авылында су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау
- урам яктыртуны карап тоту (Лельвиж авылында урам яктыртуны көйләү өчен урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм ремонтлау)
- Лельвиж авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;
- мотопомпа сатып алу
- Лельвиж авылында су суырту манарасын урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү
- спорт инвентаре сатып алу
- Авыл көне бәйрәме үткәрү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Лельвиж авыл җирлеге башлыгы Э.Ю. Игнатьева